**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 18 » декабрь 2025 ел № 16

«Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 5 декабрендәге 17 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 октябрендәге 7 номерлы карарына таянып, Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Круглое поле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 5 декабрендәге 17 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләрен бирү һәм аларны эшкәртү» сүзләренә алыштырырга;

1.2. 2.5.1 пунктының 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктчасын өстәргә:

«4.1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.Л. Маркова